СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2020 с. Сарманово № 223

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «Сарман муниципаль районы муниципаль милке реестры турындагы нигезләмәне раслау турында» 2012 нче елның 28 нче маенда кабул ителгән 63 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 51 статьясындагы 5 өлеше нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 13 сентябрендәге 573 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2012 елның 28 маендагы 63 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1). 2 пунктның өченче абзацында «күчемсез мөлкәткә карамаган башка мөлкәт» сүзләрен «күчемсез һәм күчемле әйберләргә карамаган башка мөлкәт» сүзләренә алмаштырырга.

2). 4 пунктта:

а) унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 бүлеккә күчемсез һәм күчемле әйберләргә карамаган муниципаль күчемле һәм башка мөлкәт турында белешмәләр кертелә:»;

б) түбәндәге эчтәлекле егерменче - егерме икенче абзацлар өстәргә:

«Күчемсез һәм күчемле әйберләргә карамаган башка мөлкәткә карата реестрның 2 бүлегенә шулай ук түбәндәгеләр турында белешмәләр кертелә:

- мөлкәт хокукы объектының төре һәм исеме;

күрсәтелгән мөлкәткә хокукы барлыкка килгән норматив хокукый акт,

шартнамә яисә башка документ реквизитлары нигезендә тиешле реестрдан (Россия Федерациясе уйлап табуларының дәүләт реестры, Россия Федерациясе файдалы модельләренең дәүләт реестры, Россия Федерациясе товар билгеләренең һәм хезмәт күрсәтү билгеләренең дәүләт реестры һ.б.) яисә әлеге реквизитларныраслаучы башка документка, документның исемен, сериясен һәм номерын, документны биргән дәүләт органының (оешманың) исемен һәм исемен бирү датасын да кертеп;»;

в) егерменче - утыз алтынчы абзацларны егерме өченче - утыз тугызынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» ( PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Интернет челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында , шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны экологик мәсьәләләр һәм Сарман муниципаль районы Советының инфраструктура үсеше мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы Рәисе

Ф.М.Хөснуллин